ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

26 сентябрь 2022 ел №5014

Башкарма комитет резерв фондының бюджет ассигнованиеләреннән файдалану тәртибе турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Бюджет кодексының 81 статьясы, «Россия Федерациясендә мобилизацион әзерлек һәм мобилизация турында» 1997 елның 26 февралендәге 31-ФЗ номерлы Федераль законның 8 статьясы, Россия Федерациясе Президентының «Россия Федерациясендә өлешчә мобилизация игълан итү турында» 2022 елның 21 сентябрендәге 647 номерлы Указы, шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге 19/8 номерлы карары белән расланган Муниципаль хокукый актлар системасы турында нигезләмәнең 5.24 пункты нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М :

1. Башкарма комитетның 2017 елның 9 июнендәге 3528 номерлы карары (Башкарма комитетның 2020 елның 25 мартындагы 1459 номерлы карары редакциясендә) белән расланган Башкарма комитет резерв фондының бюджет ассигнованиеләреннән файдалану тәртибе турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 4 пунктка түбәндәге эчтәлектәге 6 пунктча өстәргә:

«6) Украина, Донецк Халык Республикасы һәм Луганск Халык Республикасы территорияләрендә махсус хәрби операция барышында күздә тотылмаган чыгымнарны тәэмин итүгә, шул исәптән:

- Яр Чаллы шәһәрендә яшәүче һәм Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнарга бер тапкыр бирелә торган түләүгә.»;

2) 5 пунктта «бер тапкыр бирелә торган матди ярдәм» сүзләреннән соң «әлеге нигезләмәнең 4 пунктындагы 2 пунктчасында каралган максатлар өчен» сүзләрен өстәргә;

3) 7 пунктның икенче абзацында «3, 4, 5» цифрларыннан соң «6» цифрын өстәргә.

2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны рәсми бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы

рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары, финанс идарәсе башлыгы С.Р. Мулюковага йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Ф.Ш. Салахов